
ТАТАРСТАН ВАРИСЛАРЫ
Кырмыска хикәятләре
МУЛЬТФИЛЬМНАР КАРА

# Кырмыска әкиятләре

**Мәкальләр** – халыкның зирәклеген, хикмәтлелеген үзенә туплаган бетмәс-төкәнмәс хәзинә. Аларның кайчан һәм кайда барлыкка килүе берәүгә дә мәгълүм түгел. Мәкальләрнең асыл чыганагы – киңкырлы һәм катлаулы тормыш үзе. Халыкларның еллар, гасырлар буена тупланган тәҗрибәсеннән туган мәкальләр буыннан-буынга тапшырылып килә һәм тормышыбызны һәрьяклап колачлый.

Әкияти кырмыска халкының да хикмәтләр тулы сандыгы бар. Зирәк карт кырмыска андагы мәкальләрнең асылын кырмыска балаларына аңлата.

# ӨРГӘН ЭТТӘН ТҮГЕЛ, ӨРМӘГӘНЕННӘН САКЛАН

**Б**ервакыт без иптәшем белән дәү әниемә кунакка барырга уйладык. Юлыбыз күршеләр йорты яныннан уза. Шулчак каршыбызда зур гына йонлач бер эт пәйда булды. Безне күрүгә, каты итеп өрергә дә тотынды.

– Тешләрен ничек ыржайткан! Каптырып алырга гына тора! – дип, шүрләп калды иптәшем. – Әйдәле, урап узыйк моны.

Шулчак мин ерак түгел генә тагын бер эт торуын күреп алдым. Күрәсең, ул теге усал этнең тавышына йөгереп килгән.

– Кара, – дим иптәшемә, – анда тагын бер эт!

– Әй, анысы бит бәләкәй, аның кай җиреннән куркасың!

Без, җитәкләшеп, әкрен генә артка таба чигенә башладык. Өргән эт яныннан узып китеп, иркен суларга да өлгерми калдык, теге бәләкәй көчек безнең янга йөгереп тә килде – иптәшемнең аягыннан эләктереп тә алды!

– Ай-яй-яй! – дип кычкырып җибәрде иптәшем. – Ычкыныйк тизрәк моннан!

Кунакка килеп җиткәч, әлеге маҗара турында сөйләдек. Дәү әнием башын чайкап болай диде:

– Эх сез! Астыртын этнең өрми генә тешләвен белмисезмени соң! Кисәткән һәм куркытканнан түгел, астыртын гына һөҗүм иткәннәрдән өркергә кирәк.



# Уку – нур, укымау – хур



Укытучы парталар арасыннан йөри-йөри электр турында сөйли.

Мин аның сөйләгәнен бөтенләй тыңламыйча, кичә уйнаган футбол турында уйлап утырам.

Тик ни кызганыч, дәресләрне хәзерләргә өлгермәгән идем. Укытучы мине такта янына чыгарды.






Каршымда зур прибор тора. Анда лампочкалар, төймәләр, чыбыклар күп иде.

– Ничек кабызырга икән соң моны? – дип аптыраштa калдым.



Җентекләп карагач, зур кызыл төймә күрдем һәм аңа бастым. Үзгәреш булмады. Тагын бер бастым. Прибор кабынмады. Балалар көлешә башлады.

Минем ачуым чыкты һәм приборга китереп типтем. Ул шаулый һәм селкенә башлады.




Иң зур лампочкада нокта хәтлегенә яктылык пәйда булды. Ул бик тиз зурая башлады. Бер минуттан лампочка яп-якты булды. Прибор катырак селкенергә тотынды һәм шартлады! Сыйныф бүлмәсен караңгылык чорнап алды. Ә мине җиңелчә генә ток сукты.

Менә шулчакта мин «Уку – нур, укымау – хур» дигән сүзләрнең мәгънәсен аңладым.



# Сакланганны Аллаһ саклар



Бервакыт без дустым белән походка киттек.

Озак бардык. Алан артта калды. Ә каршыда – елга. Аның аша күпер салынган.



Мин күпер аша чыкмакчы булган идем, әмма дустым мине узып, алдан кереп китте. Такталарга баса-баса: «Нык түгел бу күпер. Җимерелеп, елгага барып төшүең дә бар. Әйдә, без елганы әйләнеп үтик!» – диде.

Без бәхәсләшергә тотындык. Минем күпер аша чыгасым килә, дустым чыкмаска куша. Шулай итеп, ачуланыштык та. Дустым үпкәләп китеп барды.



Ә мин күпер аша чыга башладым. Кинәт күпер такталары сынды, һәм мин суга барып төштем.

Бик нык курыктым, ярга таба йөзә башладым. Ә елганың агымы көчле, суы салкын. Ярга килеп җитәм дигәндә генә, дулкын мине кирегә алып китә. Ниһаять, чыктым. Еш-еш сулап ятам.





Кинәт елга борылышыннан ниндидер яшел әйбер килеп чыкты. Мин башта курыктым. Яхшылап караганнан соң, миңа ярдәмгә ашыгучы дустымны күреп алдым. Ул каен яфрагын суга этеп керткән дә, нарат энәләреннән ишкәк ясап, тиз генә йөзә башлаган.



Дустым белән бәхәсләшкәнем өчен миңа оят булып китте. Ул хаклы булып чыкты бит.

Менә шул вакытта «Сакланганны Аллаһ саклар» дигән мәкальнең асыл мәгънәсен аңладым мин.

# Кайтавазның җавабы да кире кайтыр



Дусларыбыз белән качышлы уйный идек. Мине гел беренче табалар. Мин урманга кереп качарга булдым. Як-ягыма карана-карана, урман буйлап барам шулай.



Зур гөмбәгә тап булдым. Бәлки аның артына качаргадыр? Әллә инде җир җиләге яфрагы астына керергәме? Уйланып бара торгач, мин адашканмын. Өйгә илтүче сукмакны һич кенә дә табып булмый.




«Ау! Ау!» – дип кычкырырга, урман буйлап йөгерергә тотындым. Тирә-юньдә беркем юк. Кояш баю ягына авышты, караңгы төшә башлады. Куркыныч һәм ят тавышлар ишетелә.




Бер зур таш күреп алдым, мәгарәсе дә бар. Кычкырмакчы булган идем, курка калдым. Бәлки анда берәр явыз җан яшидер? Рәнҗетер, я булмаса, тотып ашар. Тик берни эшләр хәл юк. Өйгә илтүче юлны табарга кирәк.







Башта мәгарәгә карап, пышылдап кына: «Ау…», – дидем. Аннан беркем дә чыкмады. Мин батыраеп, каты итеп: «Аууу!!!» – дип кычкырдым. Һәм кинәт мәгарәдә зур баш күренде. Ул миңа карады һәм авызын ачып: «Ррррр!!!» – диде.




Бу тавыш белән чыккан җил, мине бөтереп алып, кырмыска оясына илтеп ташлады. Югыйсә, мин өйдән ерак та булмаганмын икән.

«Кайтавазның җавабы да кире кайтыр» дип, юкка гына әйтмиләр шул.

# Суга батучы еланга ябыша



Минем яшел бөҗәк дустым бар иде. Бервакыт мин йорт хайваннары арасында ярыш уздырылачагы турында ишеттем. Мин бөҗәкне кушканнарны үтәргә – таякны алып килергә, утырыр-га, ятарга өйрәттем. Әгәр дә дустым йөзәргә дә өйрәнсә, без, һичшиксез, җиңәчәкбез.



Без елга буена килдек. Бөҗәк үлән өстенә менде. Мин: «Әйдә! Алга! Сикер!» – дип, команда бирдем. Бөҗәк курка, суга сикерергә теләми. Минем ачуым чыкты. Чыбык алдым да үлән өстеннән йөгерә башладым.

Кинәт үлән тирбәлә башлады, һәм мин суга барып төштем. Тирән, ярга кадәр дә ерак.





Мин тыпырчына башладым. Бөҗәгем борчыла, үләннәр өстеннән чаба. Кинәт ул туктады һәм миңа аягы белән нәрсәдер күрсәтә башлады.



Артыма борылып карасам, анда зур елан тора!

Авызын ачып, телен миңа таба суза башлады бу.





Куркудан, аның теленә ябыштым. Елан төрле якка бәргәләнергә тотынды.

Аста коры җир күреп, еланның телен ычкындырдым. Барып төштем һәм өйгә чаптым. Бөҗәк тә минем арттан йөгерде. Без йөзмичә дә бүләк алдык.

Шуннан бирле мин «Суга батучы еланга ябыша» дигән сүзләргә ышана башладым.

# Кеше җырын җырлама





**Б**ервакыт әни миңа әтигә эш кораллары илтеп бирергә кушты.



**Ә**ти алан читендә сууткәргеч төзәтә иде. Ул барлык коралларны да алмаган һәмниләр кирәген пәрәвезгә язып җибәргән.


Әни аларны җыйды, һәм мин киттем. Безнең алан зур. Мин арыдым һәм ял итеп алырга булдым. Үләннәр өстенә менеп, яфракка яттым.






Кинәт миңа бызылдаган тавышлар ишетелде. Бер минуттан минем яныма черкиләр очып килде. Мин аларны үртәмәкче булып, бызылдый башладым.

Черкиләр катырак бызылдадылар. Мин дә тавышымны көчәйттем. Шулкадәр мавыктым, хәтта әти турында да, аның эш кораллары турында да оныттым.



Кинәт черкиләр очып китте. Ә мин бар көчемә бызылдыйм! Тирә-як караңгыланып китте – әйтерсең, ниндидер зур әйбер кояшны каплады.



Артыма борылып карасам, анда зур гөберле бака тора.

Ул минем каты итеп бызылдавымны ишетеп килгән. Мин эш кораллары салынган әрҗәне эләктердем дә, үлән өстеннән сикереп төшеп, әти янына чаптым.

Йөгереп барганда, мин «Кеше җырын җырлама» дигән мәкальнең мәгънәсенә төшендем.



# Кешегә чокыр казыма, үзең төшәрсең



Бервакыт минем яшел бөҗәгем миңа үпкәләде. Кояшлы, матур көн иде. Бөҗәк мине урамда йөрергә чакырды. Тик миңа дәрес хәзерләргә кирәк иде. Бераздан әни кайтты.





**Б**өҗәк, сиздермичә генә, ачык ишектән чыгып киткән. Дәресләремне хәзерләп бетергәч, мин бөҗәкне чакырдым. Ул җавап бирмәде. Шунда мин ишекнең ябылып бетмәгәнлеген күреп, аның чыгып качканлыгын аңладым.



**А**ны эзләргә туры килде. Бөҗәк урманда иде. Мин аны чакырдым һәм тәм-томнар тәкъдим иттем. Тик ул минем янга килергә теләмәде. Мин тозак корырга булдым.





Алан уртасында чокыр казыдым. Бөҗәк егылып төшеп имгәнмәсен дип бик тирән дә, үзе чыга алмасын өчен бик сай да итмәдем. Чокырны яфраклар белән капладым да куаклар артына постым. Озак та үтмәстән, бөҗәк килеп җитте. Ул чокырга егылып төшмәде – яфраклар аша чыкты да китте.




Сәер! – дип уйлап куйдым мин. Куаклар артыннан чыктым да яшерен чокырга сикердем. Әлбәттә инде, яфраклар мине күтәрә алмады. Бөҗәктән зуррак булганга күрә, мин чокырдан чыга алдым.

«Кешегә чокыр казыма, үзең төшәрсең» дип ни өчен әйткәннәрен беләм инде хәзер.

# Кеше күңеле – төпсез диңгез



Бервакыт мин хәзинәләр картасы таптым. Анда безнең урман төшерелгән иде. Кара нокталар белән җир асты юлы башланган урын күрсәтелгән. Кызыл билге хәзинә яткан урынны күрсәтә.



Мин дусларымны җыйдым. Без киңәшләштек тә картаны чын дип таптык. Димәк, хәзинә эзләргә китәргә кирәк. Безгә минем бөҗәгем һәм утлы коңгыз да иярде.



Җир асты юлы чыбык-чабык өеме яныннан башлана иде. Утлы коңгыз безгә керү юлын яктыртты һәм без туннельгә кереп киттек. Дөресен әйтим – без бик курыктык.





Утлы коңгыз безнең юлыбызны яктыртып барды. Тик хәзинәгә охшаган нәрсә күренмәде. Бераздан алда нокта хәтле генә ут күренде. Ул зурая барды. Һәм менә чыгу урыны. Шунда без үзебезнең поши борынында сәяхәт кылуыбызны аңладык.





Өйгә хәзинәсез кайтырга туры килде. Мөгаен, картаны берәр шаяны төзегән булгандыр. Поши борынында йөреп кайтканнан соң, мин «Кеше күңеле – төпсез диңгез» булуын аңладым.

# Бер Кояш мең йолдыздан яктырак



**М**ин үсеп җиткәч булды бу хәл. Мин бик тә укырга ярата идем. Төрле фәннәрне өйрәндем, үзебезнең урманны әйләнеп чыктым.

Андагы һәр куакны, һәр сукмакны белә башладым. Бервакыт мин җирдә кызык калмаганын аңладым. Мине йолдызлар кызыксындыра башлады.

Без, кырмыскалар, бик кечкенә. Күктә ниләр барын күрергә кыен безгә. Һәм мин телескоп ясарга уйладым. Моның өчен күп еллар кирәк булды.

Телескоп әзер булгач, дусларым миңа елганың биек ярында обсерватория төзергә булыштылар. Һәм без анда телескопны урнаштырдык. Төннәрен килеп, мин йолдызларны күзәттем.



Еллар үтә торды. Мин һәр йолдызның исемен өйрәндем. Алар турында әкиятләр, риваятьләр дә күп икән. Шулай да Кояшка карарга батырчылык итмәдем. Һәм, ниһаять, бар кыюлыгымны туплыдым.





Таң атканын көтеп, телескопны чыгып килүче Кояшка юнәлттем. Моны эшләмәгән булсамчы!



Пыяла линзалар аша үтеп кергән якты нурлар мине әздән генә яндырмады. «Бер Кояш мең йолдыз-дан яктырак» дигән сүзләрне бик яхшы аңладым мин шулчакта.

# Кунакта рәхәт булса да, үз өеңдә яхшырак

Минем абыем бар, әниемнең энесе. Ул бик еракта яши. Кунакка сирәк килә. Ә әнием аны сагына. Мин аңа хат та язып салдым, кунакка да чакырдым. Һәм менә, ниһаять – телефон! Абыем кунакка килә! Без әни белән аның килешенә ныклап әзерләндек. Өйне җыештырдык, пәрәмәчләр пешердек.



Тик, ни кызганыч, абыем ике көнгә генә килде. Без, әлбәттә, күп нәрсәләргә өлгердек: су да коендык, балык та тоттык. Ләкин ике көн сизелми дә үтеп китте. Абыем кайтып китәргә әзерләнә башлады.



Лəкин һава торышы бозылып китте, яңгыр яварга тотынды. Рейсларны кичектерделəр. Мин моңа шатландым, тик никтер абыемның гына кəефе кырылды, борыны салынды. Мин, аның күңелен күрергə телəп, җырлый, бии, мəзəк хəллəр турында сөйли башладым. Абыем елмая, ə күзлəре барыбер моңсу.





Көтмәгәндә болытлар таралды, көн аязды. Без барыбыз бергә очу полосасына йөгердек. Абыем, туктап та тормыйча, яфрак-самолётка сикереп менде. Аның күзләре бәхеттән елмая иде. Һәм мин кунакта рәхәт булса да, үз өеңдә яхшырак булуын аңладым.

# Кашыкның кадере төшке ашта беленер


Минем дустым бер кызны ошата иде. Тик аны очрашуга чакырырга кыюлыгы җитми, курка. Һәм, ниһаять, ныклы карарга килеп, иртүк аның янына барырга җыенды. «Нишләп шулай иртә?» – дип сорадым мин аннан. «Тәвәккәлләгәч, барырга кирәк! Алайса, кичкә кадәр кыюлыгым юкка чыгарга мөмкин», – дип җавап бирде дустым.

Тик көндез бик эссе, салкын суга кереп утырасы гына килә. Дуслык авыр чакта сынала, диләр. Ничек ярдәм итеп булуы турында уйлый торгач, кичә аланда зур кашык күрүем исемә төште. Ял итүчеләр калдыргандыр инде.





Кырмыска малайларын ярдәмгә чакырдым. Без бер гөмбә янында чокыр казыдык та кашыкны шунда кадап куйдык. Аңа бау бәйләдек. Читтәрәк казык кагып, бауның икенче очын казыкка беркеттек. Кашыкны күләгә ясарлык итеп тарттырып куйдык. Хәлдән тайдык, әмма менә дигән чатыр килеп чыкты.





Гөмбә өстенә туңдырма һәм сок куйдык – кафедагы кебек булды. Мин скрипкада да уйнадым әле. Дустымның сөйгәне белән очрашуы искиткеч булды! Әнә шулай мин кашыкның кадере төшке ашта беленүен аңладым.


# Кем чанасына утырсаң, шуның җырын җырларсың



Кечкенә чагымда мин, берни эшләмичә, аланда хыялланып ятарга ярата идем.

Бервакыт минем башыма «шәкертләр» алу фикере килде. Атна буе әниемә ялвардым. Ниһаять, ул ризалашты һәм миңа ике яшел бөҗәк сатып алды. Мин аларны өйрәтә башладым.





**Я**ткан килеш командалар бирәм.Ә алар ялкауланалар. Үлән аша сикереп чыгарга теләмиләр, йөгермиләр. Алҗыттылар болар мине. Әни дөрес бөҗәкләр алмаган.



Мин күргәзмәгә киттем. Яхшы бөҗәкләр сайлап алыйм әле, дип уйладым. Аннан алар белән циркта чыгыш ясармын. Циркка да сугылдым. Кемнең ничек чыгыш ясаганын карап, трибунада утырам. Кызык хәлләр күрдем мин анда. Карт бабайның бөҗәкләре көч-хәл йөри. Матур хатын-кыз кырмысканың бөҗәкләре дә үзе кебек: беләзек, алкалар таккан.



Усал кырмысканың бөҗәкләре дә явыз, ташланырга гына торалар. Мин шунда бөҗәкләремнең нигә ялкау булуларын аңладым. Кем әйтмешли, кемнең арбасына утырсаң, шуның җырын җырларсың.



# Эш беткәч, уйнарга ярый

**М**инем дустым бар иде. Бервакыт ул дошманнарга каршы яуга китә. Дошманнарны җиңә, ләкин бер аягын югалта. Йөгерү түгел, йөрү дә авыр аңа хәзер.



**У**йлый торгач, пират булырга карар кыла ул. Усал булганга түгел, ә корабленең палубасы кечкенә булганга. Анда бер аякта сикереп тә бөтен нәрсәне эшләп була. Күзенә кара бәйләвеч бәйли дә йөзеп китә бу.





**А**ның алда үзен ни көткәнен күрәсе килә, тик ерактан карый торган торбасы булмый. Тота да агачтан ясый.

**Я**л итәсе килсә, урындык юк. Аны ясап куя. Ашарга утырса, өстәле юк. Шулай итеп өстәл, штурвал, мачта пәйда була.





Кызып китеп, үзенә аяк та әмәлләп куя. Иркен сулап, биергә тотына. Юкка гына: эш беткәч, уйнарга ярый, дип әйтмиләр безнең халыкта.

ТАТАРСТАН ВАРИСЛАРЫ

Книга издана при поддержке Комиссии при
Президенте Республики Татарстан по вопросам
сохранения и развития татарского языка

# Кырмыска әкиятләре

**Әдәби-анимацион басма**

Проектның продюсеры **Азат Ганиев**
Проектның җитәкчесе **Алсу Низамеева**
Баш режиссёр **Сергей Киатров**
Әдәби мөхәррирләре: **Румия Юналеева, Алсу Низамеева, Фансәя Сафина**
Рәссамнары: **Светлана Масальских, Анна Гаранина, Әлфия Хусаинова, Арина Карпова**
Техник мөхәррире һәм компьютерда биткә салучысы **Дмитрий Гиацинтов**
Техник җитәкчесе **Дамир Бариев**

**«Татармультфильм» берләшмәсе анимациясе**

**© Татар балалар нәшрияты**
**www.tdpress.ru**

Татарское детское издательство
420124, г. Казань, ул. Сулеймановой, 5.
www.tdpress.ru

Подписано в печать 15.01.2021.
Печать офсетная. Тираж 2000 экз. Заказ №
Отпечатано в полном соответствии с качеством предоставленных
Татарским детским издательством материалов в типографии филиала
АО «ТАТМЕДИА» «ПИК «Идель-Пресс».
420066, г. Казань, ул. Декабристов, 2.

ISBN 978-5-9500141-0-9

Татармультфильм

МУЛЬТФИЛЬМНАР КАРА